ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАБАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТӘБӘРЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2025 Тәбәрле авылы № 11

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрлеавыл җирлеге башкарма комитетының «Агачларны, куакларны газонны кисү, формалаштыру һәм күчереп утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрлеавыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләти урман фондына һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында"гы 2021 елның 12 февралендә кабул ителгән 7-1 номерлы карарын, Әгерҗе районы прокуратурасының 11.03.2025-02-08-2025/Прдп112-25-20920003/59 номерлы протестын исәпкә алып Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге башкарма комитеты карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге башкарма комитетының «Агачларны, куакларны, газонны формалаштыруга, сүтүгә һәм күчереп утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 06.09.2021 кабул ителгән 18 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 3.5.2.1 пунктының 7 абзацын, 3.5.2.2 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең бәясен һәм компенсацион яшелләндерү Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге башкарма комитетының 2025елның 25

августының 10 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү методикасын раслау турында”гы карары нигезендә исәпләп чыгара”

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Әгерҗе муниципаль районының официаль сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәренә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

